**III ЧАКЫРЫЛЫШ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**“ЯҢА АЛЕКСАНДРОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ”**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**XXXXXX СЕССИЯ**

**КЫРЫК СИГЕЗЕНЧЕ СЕССИЯ**

**1нче КАРАР**

Яңа Александровка авылы «23» июль, 2019 ел

**Бөгелмә муниципаль районы**
**Яңа Александровка авыл җирлеге Советының**
**2019 елның 20 маенда булып узган**
**44нче сессиясендә кабул ителгән**
**“Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы**
**“Яңа Александровка авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә**
**гавами тыңлауларны оештыру**
**һәм уздыру тәртибе турында”гы нигезләмә турында»гы 5нче карарга**
**үзгәрешләр кертү турында**

Законнарга туры китерү максатында һәм Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Яңа Александровка авыл җирлеге Уставына таянып,

**Яңа Александровка авыл җирлеге Советы**

**КАРАР БИРДЕ:**

Бөгелмә муниципаль районы Яңа Александровка авыл җирлеге Советының 2019 елның 20 маенда булып узган 44нче сессиясендә кабул ителгән “Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы “Яңа Александровка авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турында”гы нигезләмә турында»гы 5нче карарга түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 2нче бүлектә:

1.1. 2.2нче пунктның 1нче аспунктын яңа басмада бәян итәргә:

“1) “Яңа Александровка авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы проекты, шулай ук әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы муниципаль хокукый-норматив акты проекты, муниципаль берәмлек Уставына үзгәрешләр Россия Федерациясе Конституциясендәге, федераль законнардагы, Россия Федерациясе субъекты Конституциясе (Уставы) яки законнарындагы нигезләмәләрне, шул хокукый-норматив актларга туры китереп, төгәл китерү формасындагы кертелү очракларыннан тыш”;

1.2. 2.2нче пунктның 3нче аспунктын яңа басмада бәян итәргә:

“3) муниципаль берәмлекне үзгәртеп кору турындагы сораулар, – 2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән №131-ФЗ Федераль законының 13нче маддәсенә ярашлы рәвештә, муниципаль берәмлекне үзгәртеп кору өчен муниципаль берәмлек халкының тавыш бирү тәртибендә яки гражданнар җыенында белдергән ризалыгы кирәк булган очраклардан тыш.”.

3. Әлеге карар күмәк мәгълүмат чараларында рәсми төстә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемдә калдырам.

**“Яңа Александровка авыл җирлеге”**
**муниципаль берәмлеге башлыгы** **Е.Г. Гыйрфанова**